**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.12.2016 № 702

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 11 гыйнварында теркәлде, № 3782

2017 елда балигъ булмаганнарга һәм эшсез гражданнарга вакытлыча эшкә урнашу чорына матди ярдәм күләме турында

“2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең мәшгульлегенә ярдәм итү” дәүләт программасын раслау турында” 09.08.2013 ел, № 553 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, боерык бирәм:

1. 2017 елга матди ярдәм күләмнәрен билгеләргә:

14тән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган граждапннарга вакытлыча эшкә урнашу чорына, аена бер кешегә, эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 1,5 тапкырга тигез булган күләмендә;

түләүле иҗтимагый эшләрдә катнашучы эшсез гражданнарга, аена бер кешегә, эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 2,5 тапкырга тигез булган күләмендә;

эш эзләп табуда кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарга вакытлыча эшкә урнашу чорына, аена бер кешегә, эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 2,5 тапкырга тигез булган күләмендә;

урта һөнәри белемгә ия булып, тәүге тапкыр эш эзләүче 18дән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарга вакытлыча эшкә урнашу чорына, аена бер кешегә, эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 2,5 тапкырга тигез булган күләмендә;

гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлап чыгучылар арасыннан эшсез гражданнарга вакытлыча эшкә урнашу чорына, аена бер кешегә, эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 2,5 тапкырга тигез булган күләмендә.

2. Бу боерык 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары К.А. Таҗетдиновага йөкләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова